РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » 04 2021ел №293

Торак урыны мәйданының
исәп-хисап нормасы һәм социаль наем
шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын
бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 маддәләрен гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль наем шартнамәләр буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында бер гражданга торак урынының гомуми мәйданы 18 кв. метр күләмендә билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. 2019 елның 10 июлендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак урыннары бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында»гы 474 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Татарстан Республикас
Ютазы муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесе С.П.Самонина

Н.А. Абильтарова
2-76-81